**ГЛАВА АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 13 от 24.02.2026

**«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы звеносы турында»Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә

**карар итәм:**

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы звеносы турында» Апас муниципаль районы Башлыгының 2021 елның 11 мартындагы 20 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче бүлектә

икенче абзацта "янгын куркынычсызлыгы," сүзләреннән соң "гражданнар оборонасы,"сүзләрен өстәргә.;

өченче абзацта ", шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә"сүзләрен өстәргә.;

дүртенче абзацта ", шулай ук гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүгә"сүзләрен өстәргә.;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә районның муниципаль программаларын эшләүдә катнаша һәм аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр әзерли;";

алтынчы абзацта ", шулай ук гражданнар оборонасы эшчәнлеге " сүзләрен өстәргә.;

җиденче абзацта ", шулай ук гражданнар оборонасы өлкәсендә"сүзләрен өстәргә.;

сигезенче абзацта "күрсәтелгән гадәттән тыш хәлләр" сүзләреннән соң "мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар"сүзләрен өстәргә.;

түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

"Гражданнар оборонасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли;";

түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча муниципаль гамәлләр планын эшләүне оештыра.»;

түбәндәге эчтәлекле ундүртенче абзац өстәргә::

"Комиссия карарларының үтәлешен тикшереп тора.».

**Башлык** **А. Г. Җиһаншин**